ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ
ВЕРХНЕУСЛОНСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ЮГАРЫ ОСЛАН
МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ
БАШКАРМА КОМИТЕТЫ

ПОСТАНОВЛЕНИЕ КАРАР

_______________ с. Верхний Услон _______________

"Торак урыннарына мохтаҗ гражданнарның аерым категорияләрен исәпкә кую буенча муниципаль хезмәт күрсәтүнең административ регламентын раслау турында" Татарстан Республикасы Югары Ослан муниципаль районы Башкарма комитетының 2021 елның 26 февраленнән 177 нче карарына үзгәрешләр кертү хакында

“Дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтүне оештыру турында” 2010 елның 27 июлендәге 210-ФЗ номерлы Федераль законны гамәлгә ашыру максатларында, “Татарстан Республикасы дәүләт хакимиятенең башкарма органнары тарафыннан дәүләт хезмәтләре күрсәтүнең административ регламентларын эшләү һәм раслау тәртибен һәм раслау турында һәм Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының аерым карарларына үзгәрешләр кертү хакында” Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2010 елның 02 июлендәге 880 номерлы карарына таянып, “Россия Федерациясе пенсия һәм социаль иминиятләштерү фонды турында” 2022 елның 14 июлендәге 236-ФЗ номерлы Федераль законга нигезләнеп,Татарстан Республикасы башкарма хакимияте органнары тарафыннан дәүләт хезмәтләре күрсәтүнең административ регламентларын эшләү һәм раслау тәртибе нигезендә, Татарстан Республикасы Югары Ослан муниципаль районы Уставына таянып, Татарстан Республикасы Югары Ослан муниципаль районы башкарма комитеты

КАРАР БИРӘ:

1. "Торак урыннарына мохтаҗ гражданнарның аерым категорияләрен исәпкә кую буенча муниципаль хезмәт күрсәтүнең административ регламентын раслау турында" Татарстан Республикасы Югары Ослан муниципаль районы Башкарма комитетының 2021 елның 26 февраленнән 177 нче карарына түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1.1. 2.6 пунктның 3 пунктчасы һәм 3.5.1 п. «Россия Федерациясе Пенсия фонды органы» сүзләрен «Россия Федерациясе пенсия һәм социаль иминләштерү фонды органы» сүзләренә алмаштырырга.

2. Әлеге карарны Интернет мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә веб-адрес буенча Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында: http://pravo.tatarstan.ru һәм Югары Ослан муниципаль районының веб-телекоммуникация челтәрендәге рәсми сайтында веб-адрес буенча: https://verhniy-uslon.tatarstan.ru. урнаштырырга.

4. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны Татарстан Республикасы Югары Ослан муниципаль районы Башкарма комитеты җитәкчесенең беренче урынбасары М.М. Черменскийга йөкләргә

Башкарма комитеты җитәкчесе И. И. Шакиров

Әзерләде һәм бастырды:
Бурдина Т. Н. 4 нөсхәдә